РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

«22» апреля 2020 с. Тюлячи № 187

Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 3 октябрендәге 921 номерлы «Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын төзү һәм реестрын алып бару тәртибен, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибен, Теләче муниципаль районы территориясендә муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурста катнашу өчен гаризаларның критерийларын бәяләү өчен дәрәҗә күрсәткечләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

2018 елның 11 апрелендәге "Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында" Федераль законны гамәлгә ашыру турында" Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында" 22-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законына таянып, Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының 2016 елның 3 октябрендәге 921 номерлы «Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын төзү һәм реестрын алып бару тәртибен, даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү һәм туктату тәртибен, Теләче муниципаль районы территориясендә муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру хокукына ачык конкурста катнашу өчен гаризаларның критерийларын бәяләү өчен дәрәҗә күрсәткечләрен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) Теләче муниципаль районы территориясендә даими пассажирлар йөртү буенча муниципаль маршрутларны билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгару Тәртибенә:

А) III Кисәк:

- 3.4 пунктны түбәндәге тәртиптә бәян итәргә:

«3.4. Әгәр дә азрак сроклар даими пассажирлар йөртү муниципаль маршруты буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклык бирелгән юридик зат, индивидуаль эшкуар яки гади ширкәт шартнамәсендә катнашучы белән килешенмәсә, мондый таныклыкның гамәлдә булу срогы дәвамында Башкарма комитет инициативасы буенча тиешле маршрутны үзгәртү яисә юкка чыгару турында мондый карар гамәлдә булу срогы тәмамланганчы 180 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә һәм мондый таныклыкның гамәлдә булу срогы тәмамланганнан соң үз көченә керә.

Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органы яисә әлеге статьяның 6 өлешендә каралган җирле үзидарә органы тарафыннан даими пассажирлар йөртү муниципаль маршрутын, муниципальара маршрутны үзгәртү турында Карар кабул ителгәннән соң 60 көн эчендә юридик зат, әлеге маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыру турында таныклыклар бирелгән гади ширкәт шартнамәсендә вәкаләтле катнашучы индивидуаль эшкуар, мондый таныклыкларны һәм маршрутларның карталарын киләсе вакытка озайту турында гаризалар белән Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең вәкаләтле органына яисә җирле үзидарәнең вәкаләтле органына мөрәҗәгать итәргә тиеш.».

2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары вазифаларын башкаручы И.Х. Хәмидуллинга йөкләргә.

Җитәкче Н.Н. Хаҗипов